СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 4-7 от «10» июня 2021 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 29 декабрендәге №468-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131 - ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Мамадыш муниципаль районы Советының 2018 елның 19 ноябрендәге 5 - 29 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә» (23.07.2019 №15-34 редакциядә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 29 статьяда:

- Җир участокларын һәм капиталь төзелеш объектларын куллану рөхсәт ителгән иң чик параметрлар таблицасында минималь мәйданны 1000 кв. м., максималь мәйданны 2500 кв. м. дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетына (Башкарма комитетның инфраструктур үсеш бүлегенә) әлеге карарны һәм «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен расланган көннән алып биш көн эчендә территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны һәм «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://mamadysh.tatarstan.ru һәм

000038

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында pravo.tatarstan.ru адреслары буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының Җирле үзидарә, аграр сәясәт, җирдән файдалану һәм экология буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
башлыгы, Совет рәисе А.П. Иванов